KÜLTÜRK

***KÜLTÜRK** Türk Dili ve Edebiyatı Araştırmaları Dergisi, Sayı: 1 (Yaz 2020), s.83-92.*
***KÜLTÜRK** The Journal of Turkish Language and Literature Studies, Issue: 1 (Summer 2020), pp. 83-92.*

*Geliş Tarihi / Received: 05/06/2020 Kabul Tarihi / Accepted: 16/06/2020*

# ULUSAL EDEBİYAT ALANINDA CENGİZ AYTMATOV'UN ESERLERİ

## CHINGIZ AITMATOV'S CREATIVITY IN THE NATIONAL LITERARY FIELD

**Prof. Dr. Flera SAYFULİNA**

Kazan Federal Üniversitesi

Tataristan / Rusya

**E-posta**: fsaifulina@mail.ru

**Orcid:** 0000-0001-5623-4269

## Öz

Bu makalede, Tatar çeviri okulunun faaliyetlerini incelemek maksadıyla ünlü yazar Cengiz Aytmatov'un eserlerinin tercümelerine odaklanılmıştır. Tatar çeviri okulunun yüz yıllık bir geçmişi vardır. 20. yüzyılın ikinci yarısında, Sovyet döneminin Rusça konuşan yazarlarının eserleri faal bir biçimde tercüme edilmiştir.

Hem millî edebiyat hem de Rus ve dünya edebiyatı tarihini etkileyen Aytmatov'un eserleri Tatarcaya çevrilmiştir. Onun eserlerinin Tatar edebiyatının ruhuna bu denli çok yaklaşmasında annesinin Tatar asillerinden "Khamza Gabdulvalieva" olmasının çok büyük payı vardır. Aytmatov'un "Jamilya", "Kırmızı Başörtüsü'ndeki guzelim benim", "Annemin Alanı", "Camel'in Gözü" gibi birçok romanı Tatarcaya çevrilmiştir. Aynı zamanda yazarların bazı eserleri Tataristan Cumhuriyeti'nin ünlü tiyatrolarında da sahnelenmiştir.

XXI. Yüzyılın başında Türkçe konuşan yazarların eserleri Tatarcaya faal bir biçimde tercüme edilmiştir. Ayrıca Tatar yazarlarının eserleri Türkçe, Kazakça ve diğer Türk lehçelerine de çevrilmiştir. Eserlerin başka dillere çevrilmesi halkları birbirine yaklaştırır, halkların karşılıklı anlayışına hizmet eder. Bu noktadan hareketle yaptığımız bu incelemede Cengiz Aytmatov'un eserleri ulusal edebiyat bağlamında ele alınmıştır.

**Anahtar Kelimeler:** Tatar edebiyatı, çeviri, Cengiz Aytmatov'un mirası, edebî çeviriler.

## Abstract

This article focuses on the translations of Chingiz Aitmatov's works. The Tatar translation school has a hundred-year-old. In the second half of the 20th century, the works of the authors in the Russian language of the Soviet era are actively translated.

The works of Aitmatov, which influenced both national literature and the history of Russian and world literature, have been translated into Tatar. The fact that his mother is "Khamza Gabdulvalieva" has a great role in his works getting so close to the spirit of Tatar literature. Many novels of Aytmatov such as "Jamilya", "My beauty in the Red Headscarf", "My Mother's Field" and "The Eye of Camel" have been translated into Tatar. At the same time, some of the writers' works were staged in the famous theaters of the Republic of Tatarstan.

Some of the writer's works were staged in the famous theaters of the Republic of Tatarstan. At the beginning of the XXI century, works of Turkic-speaking writers were actively translated into Tatar. And also works of Tatar writers are translated into Turkish, Kazakh and other Turkic languages. Translation of works into other languages brings peoples closer together, serves the mutual understanding of peoples. From this point of view, the works of Chingiz Aitmatov have been handled in the context of national literature in this examination.

**Key words**: Tatar literature, translation, the creative heritage of Chingiz Aitmatov, literary translations.

**Аннотация**

Данная статья посвящена исследованию перевода произведений известного писателя Чингизыа Айтматова в контексте изучения деятельности татарской переводческой школы. Татарская переводческая школа имеет вековую историю. Особо активно переводились на татарский язык произведения русскоязычных писателей советского периода – во второй половине XX столетия.

Многие произведения Ч. Айтматова, определяющие целую эпоху в истории, как национальной, так и российской и мировой литературы, переведены в свое время на татарский язык. Его творчество очень близко по духу к татарской литературе, так как корни писателя со стороны матери исторически происходят от знатной татарской семьи Хамзы Габдулвалиева. В свое время переведены на татарский язык многие повести Айтматова, такие как «Джамиля», «Пополек мой в красной косынке», «Материнское поле», «Верблюжий глаз»; романы – «И дольше века длится день», «Плаха» и другие.

Некоторые произведения писателя ставились в известных театрах Республики Татарстан. В начале XXI века активно начали переводиться на татарский язык произведения тюркоязычных писателей. А также произведения татарских писателей переводятся на турецкий, казахский и др. тюркские языки. Перевод произведений на другие языки сближает людей, служит взаимопониманию народов.

**Ключевые слова.** Татарская литература, переводческая деятельность, творческое наследие Ч.Айтматова, литературные переводы.

## ТВОРЧЕСТВО ЧИНГИЗА АЙТМАТОВА В НАЦИОНАЛЬНОМ ЛИТЕРАТУРНОМ ПРОСТРАНСТВЕ

Чыңгыз Айтматов – XX йөзъелнның икенче яртысында иҗат иткән дөнья әдәбиятының иң күркәм үрнәкләрен тудырган язучы. Үзе исән вакытында ук укучыларның мәхәббәтен казанган, Россиянең күпмилләтле әдәбиятыннан иң күренекле урынны яулаган прозаик. Бөтен дөньяга кыргыз халкын, аның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен, ышануларын таныткан язучы – татар халкы өчен дә кадерле шәхес. Әлеге милли язучы дөнья аренасына чыгып, бөтеньдөнья күләмендә танылу алды: чөнки аның иҗатында Шәрык халкының фәлсәфәсе дөнья мәдәнияте традицияләре белән бәйләп үстерелде. Монда Европа һәм Азиянең фундаменталь кыйммәтләре кисешә: шул сәбәпле аның әсәрләре гомумҗәмгыяти яңгыраш алды.

Бөек тарихы булган татар халкы – Чыңгыз Айтматовны үз улы буларак кабул итте, аның иҗатына битараф булмады. Бу якынлык – булачак язучының әнисенең туганлык тамырлары Татарстаннның Кукмара районы Мәчкәрә авылыннан булуы белән аңлатыла. «Ч.Айтматовның әнисе ягыннан токымы Татарстан Республикасының Кукмара районнында XIX гасырдан яшәүләре билгеле. Язучының бабасы Хәмзә Габделвәлиев 1нче гильдия татар сәүдәгәре була. Мәчкәрә авылында алар 2 мәчет төзиләр. Аның XIX йөзъелның 70-нче елларнида

энесе Әхмәтгали һәм сеңелесе Галия белән туган якларыннан чыгып китүләре билгеле. Алар Урта Азиягә юл тоталар». (Хабутдинова, 2013: 270-276) Алар гаиләсе озын юл үтеп, Кыргызстан җирләрендә, Ыссыккүл буйларында төпләнеп калганнар. Мәчкәрә авылында әлеге нәсел белән бәйле 22 кабер ташы саклананган.

Чыңгыз Айтматовның әнисе Нәгыймә хакында татар язучысы Фәүзия Бәйрәмова тарафыннан «Ана» исемле әсәр язган. (Бәйрәмова, 2015: 176) Әлеге китапның язылу тарихы турында язучы түбәндәге фикерләрне сөйли: «Кыргызстанда кемнән генә сорама, татарга мөнәсәбәте бар кебек тоелды миңа. Күбесе «минем әбием татар булган» дип сөйләде. Татар кызы зыялы, берничә тел белә, менә дигән ана бит ул. Ә Нәгыймә апаны тормыш бер күтәрә, бер җиргә бәрә. Мәдрәсә-гимназияләрдә укыган татар кызы, дүрт бала анасы әнә шулай сынала. Иренең атып үтерелгәнен дә белмичә күпме яши. Баш өстендә болытлар куерганын сизгән гаилә башлыгы аңа туган ягына кайтырга куша. Ирнең туганнары шушы дүрт баланы бүреләр кебек саклап үстерәләр. Үзләре ачтан үләләр, халык дошманы балаларын сыендырдың дип кулга алыналар, җаннары кыела, әмма Нәгыймә апаны, балаларын урамда калдырмыйлар, кыек карамыйлар. Бу яктан без кыргыз халкына рәхмәтле булырга тиеш». (http://matbugat.ru/) Әлеге китапка Нәгыймә Габделвәлиева-Айтматова язмышы гына түгел, кыргыз-казах далаларына чыгып китеп, шунда төпләнеп калган милләттәшләребезнең дә шатлык-фаҗигаләре сыйган. Язучы әйтүенчә, ул Ана образы аша татар тормышына бәя биргән, милләт тарихындагы табышларны, югалтуларны барлаган, нәсел саклап калуда ана ролен чагылдырган.

1994 елга кадәр кабере дә билгеле булмаган этисе, гомерен 4 баласын үстереп, аякка бастыруга багышлаган әнисе алдындагы бурычын Чыңгыз Айтматов әдәби әсәрләре аша түли, әлеге җәхәттән караганда язучының «Анам кыры» әсәре аеруча зур игътибарга лаеклы әсәр.

Татарстан Республикасының беренче призеденты Минтимер Шәрип улы Шәймиев белән очрашу вакынында (2006 ел, 21 февраль) Чыңгыз Айтматов үзе Казан шәһәренә «магик (тылсымлы) сыйфатлы» «бик тирән тугандаш хисләр» тоюы хакында әйтә, моны ул әнисе ягыннан гаиләсе тамырларының Татарстанга бәйләнгән булуы белән аңлата. (ИА "Татар-информ"). Шул очрашуында язучы татар укымышлылары-зыялыларының, дин әһелләренең Урта Азия халыклары, шул исәптән кыргызларның да, милли мәдәниятен формалаштыруда зур роль уйнауларын әйтеп үтә.

Вафатыннан бераз алдарак Чыңгыз Айтматов янә Казанга килә, «Бер көн – бер гомер» романы буенча фильм төшерү уе белән йөри, әнисе, бабасының туган

җирен зыярәт итергә бару теләген белдерә. Ләкин әлеге сәфәр язучы өчен соңгысы була: ул әнисен биргән туфракка баш ия алмый кала.

Соңгы дистә елларда фәнни форумнарда еш кына төрки телләр өчен гомуми төрки тел тудыру яки төрки язучылар иҗатын тугандаш телләргә тәрҗемә итү кирәклеге хакында шактый еш ишетергә туры килә. Әлбәттә, XIX йөзьелда ук Исмәгыйль бәй Гаспралы тарафыннан күтәрелгән әлеге мәсьәлә бүгенге көндә дә әһәмиятен югалтмый. Русия җәмгыятендә 1990 елларда булган үзгәрешләр татарларга төрки халыклар белән якынрак аралашу мөмкинлеген тудырды. Шулай да әдәби әсәрләрне башка телләргә тәрҗемә итү – татар язучылары өчен һәрвакыт актуаль мәсьәлә булып торуын билгеләп үтергә мөмкин. Әлеге мәсьәләгә багышлап төрле киңәшмәләр дә үткәрелүе билгеле. (Татар әдәбияты тарихы, 2001: 7). Тәрҗемә эше бүгенге көндә әдәби бәйләнешләрне тормышка ашыруның бер юлы буларак карала (Татар әдәбияты тарихы, 2015: 470). Әдәбият белеме галиме Х. Миңнегулов тәрҗемә эшенең гаять киңкырлы һәм әһәмиятле функция башкаруына басым ясый: «Тәрҗемә – гадәти лингвистик яки әдәби күренеш кенә түгел, ә үзара аңлашуның, рухи, мәгълүмати байлыклар белән танышуның гаять мөһим чарасы да. Ул кешеләрне, халыкларны, илләрне, чорларны якынайта, аларның үзара сөхбәт-диалогларын тәэмин итә» (Миңнегулов, 2010: 219).

Әлеге юнәлештәге хезмәттәшлек укучыларны кардәш халыкларның алдынгы әдәбият әсәрләре белән таныштыру өчен, шулай ук, татар әдәбиятын төрки милләтләр мөхитендә таныту өчен дә зур мөмкинчелек ача. Чыңгыз Айтматов иҗаты – моның уңай үрнәге булып тора ала.

Чыңгыз Айтматов әсәрләре – иҗат ителү вакытында ук дөньяның 200гә якын теленә тәрҗемә ителүе мәгълум. Әлбәттә, үз заманында ук классик дәрәҗәсенә ирешкән язучының иҗаты татар телендә дә дөнья күрә. Татар тәрҗемә мәктәбе традицияләре хакында сөйләгәндә, совет чорында шактый күп рус телле язучыларның әсәрләренең татар теленә тәрҗемә ителүен билгеләп үтергә мөмкин. XX гасырның урталарыннан 1980 елларга кадәр республиканың үзәк нәшрияте булган Татарстан китап нәшриятендә һәр ел саен дистәләрчә рус һәм башка милли телләрдән тәрҗемә ителгән китаплар басылып чыга. Әлеге сан гомуми басылып чыккан әдәби китапларнын 10% ка якын өлешен тәшкил итә. Дистәләгән рус язучылары белән бергә милли әдәбиятлардан – казах язучысы Абай Кунанбаев, Мөхтәр Ауэзов, Сабит Муканов, үзбәк шагыйре – Әскәд Мөхтәр, грузин язучысы Нодар Думбадзе һәм башка бик күпләрнең әсәрләре тәрҗемә ителә. Чыңгыз Айтматовның һәр әсәре диярлек үз вакытында ук татар теленә –

язучының әнисе теленә тәрҗемә ителеп, татар укучысына җиткерелеп тора (Хамидуллин, 2012).

Чыңгыз Айтматов иҗатында Русия әдәбиятындагы күпъеллык торгынлык чорыннан соң халык тарихы белән бергә кеше язмышына, милли яшәү рәвешенә, милли-әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләргә аеруча зур игътибар бирелә. Ч.Айтматовны дөньяга таныткан беренче әсәре - «Җәмилә» (1958) повесте булды (Айтматов, 1962: 88).

Әлеге әсәр татар тарихчысы – Миркасыйм Госманов тарафыннан (1962) татар теленә тәрҗемә ителеп, беренчеләрдән булып Айтматов исемен татар халкына танытты. Әлбәттә, тугандаш халыклар тормышы нигезендә тудырылган бөтен каршылыкларны да җиңеп чыккан мәхәббәт тарихы, хатын-кызның җәмгыяттә танылуы мәсьәләсе татар укучысында да зур кызыксыну уятты.

Ч.Айтматовның моннан соңгы һәр әсәре дә татарлар арасында кызыксыну белән көтеп алына. 1961 елда Чыңгыз Терекулла улының рус телендә «Кызыл яулыклы тирәгем минем» дип аталган әсәре татарның талантлы язучысы Хәсән Сарьян тәрҗемәсендә «Гүзәлем Әсәл» исеме белән басылып чыга. (Айтматов, 1965: 120). Әсәр мәхәббәткә тугрылык кебек мәңгелек темага багышланган. Кыргыз теленнән язучының нәкъ менә әлеге әсәренең татар теленә уңышлы тәрҗемә ителгән булуына басым ясап әйтергә мөмкин. Аның сәбәбе дә ачык: тәрҗемә авторы язучы булуыннан тыш, тел белеме, әдәби тәнкыйть һәм тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Х.Сәрьян татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүдә актив катнаша, радиода чыгышлар ясый, әдәби иҗат осталыгы, тел сафлыгы хакында фикерләр алышуда катнаша. Болар тәрҗемәчегә тугандаш халык теленең бөтен байлыгын һәм гүзәллеген укучыларга җиткерергә ярдәм иткән.

"Гүзәлем Әсәл" әсәренең 1966 елда Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелуы да аның укучыны кызыксындырырлык сюжетка корылган, мәңгелек мәхәббәт һәм нәфрәт темасына багышланган булуы белән бәйле. Әсәл ролен беренче булып Найлә Гәрәева, Ильяс роле – Ринат Тәҗетдинов башкаруында укучыларга җиткерелә. Әлеге әсәрнең сәхнәгә куелуы – татар театрында зур вакыйга буларак кабул телә, сәхнә әнкыйтьчеләре тарафыннан тәфсилле анализ ясала, бәя бирелә. (Саликова, 1966: 8; Илялова, 1966: 28; Сахновский-Панкеев, 1967: 70). Әсәр Татарстанның иң югары премиясе – Г.Тукай исемендәге бүләккә лаек була, күп тапкырлар сәхнәдә уйнала.

Беренче карашка шактый гадәти тоелган сюжет сызыгында каһарманнарның драматик кичерешләре, тормыш авырлыклары алдында хисләренең ныклыкка сынау үтүе әлеге тарихны кызыклы һәм кабатланмас итә. Тамашачы алдына әле һаман да җавап табылмаган мәңгелек сораулар куела һәм һәркем аларны

спектакль барышында үзенчә чишә. Язмышның беренче сикәлтәләре Ильясны нигә адаштыра, чын бәхетнең кадерен аңлар өчен Байтимер кебек тормышның ачысын-төчесен татырга, югалтулар аша олы сөюеңне табарга кирәкме? Мәхәббәте өчен туган йортыннан ваз кичәргә мәҗбүр булган, җан сөйгәненең хыянәте белән очрашкан Әсәл хатын-кыз бәхетенә лаекмы? Чыңгыз Айтматов тормыш хакыйкатенең янәшәдә генә булуын классикларга хас зирәклек белән тамашачыга җиткерә.

2016 елда "Гүзәлем Әсәл" әсәренең Габдулла Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театры артистлары тарафыннан (куючы-режессеры – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин) яңадан сәхнәләштерелүе – әсәрнең бүгенге көндә дә укучыны кызыксындыруы, әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләрнең мәңгелек булуы белән аңлатыла.

Әлеге әсәрдән соң Ч.Айтматов тарафыннан бер-бер артлы «Беренче укытучы» (1962), әсәре бастырыла. 1965 елга кадәр Ч.Айтматовның кыргыз телендә язуы билгеле. Аның рус телендә бастырылган беренче повесте «Бәхил бул, Гөлсары!» әсәре. 1976 нчы елда язучының «Повестлар» дип аталган китабы дөнья күрә. (Айтматов, 1976: 320) Әлеге китапка кергән «Бәхил бул, Гөлсары!», «Анам кыры», «Дөя күзе» певостьләре дә татар теленә Я. Хәлитов тарафыннан тәрҗемә ителә.

Әлеге тәрҗемәләрнең авторы Яхъя Хәлитов күп елар татар телендә гасыр дәвамында басылып килгән әдәби журнал - «Казан утлары»ны редакциясендә һәм Татар китап нәшриятендә хезмәт итә. Ул гомерен тәрҗемәчелек эшенә багышлаган шәхесләрнең берсе. 1952 елдан башлап ул күп кенә рус язучыларының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә: аның къп еллык хезмәт юлында иң оста тәрҗемә ителгән эшләре буларак, Ч.Айтматов әсәрләре исәпләнә.

Ч. Айтматов тарафыннан иҗат ителгән беренче зур күләмле роман «Бер көн – бер гомер» (1980, русча "Дольше века длится день) әсәре 1990 елда татар теленә танылган әдәбиятчы Рим Шириязданов тарафыннан тәрҗемә итеп, бастырыла. (Айтматов, 1990: 288) Әлеге романның тәрҗемәсе, оригиналы кебек үк киң җәмгыяти кыйммәткә ия була «Манкорт» төшенчәсе татар теле лексикасына кереп, замана кешесе тормышында булган зур үзгәрешне – шәхеснең үз токым-тамырларыннан аерылуын, буыннар бәйләнеше өзелүен чагылдыручы тирән мәгънәле сүзгә әйләнде.

1986 елда язучының танылган әсәре «Ахырзаман» (русча "Плаха) әсәре басылып чыга һәм әлеге әсәр дә тиз арада татарчага тәрҗемә ителә. Әлеге әсәрендә Чыңгыз Айтматовның үз заманының иң катлаулы мәсьәләләрне күтәргән бу әсәре дә укучыны битараф калдырмый. Татарстанда әлеге әсәрнең

язмышы да уңай хәл ителә: әсәр мотивлары буенча куелган Академия театры сәхнәсендә куелган замананың актуаль мәсьәләләреннән берсе булган табигатьне саклау мәсьәләсе хакында гына түгел, кеше күңелендә булган зур афәтләр – кешелеклелек сыйфатлары югалу турында уйланырга этәреш ясаган әлеге спектакль караучыларны тетрәндерә, кешелекнең үзенең соңгы көненә таба баруын искәртә, уйланырга, үзгәрергә, җанлы табигатькә мөнәсәбәтне төзәтергә чакыра.

Русиядә әлеге сюжеты ягынна катлаулы һәм фикер тирәнлеге, кискенлеге белән аерылып торган катлаулы романны беренчеләрдән театр сәхнәсенә куючылар буларак – татар драматургы Мансур Гыйләҗев (танылган татар язучысы Аяз Гыйләҗевнең улы) һәм куючы-режессер Дамир Сиразиевне атарга була. Әсәр 1987 елда Татарстан Академия театры сәхнәсендә уйнала. «Бүгенге көндә 30 яшьтән артыграк булган безнең буын язмышы, җиңел генә хәл ителми. Кискен үзгәреш вакыты безнең тормышны да ике өзеккә бүлә кебек: «әлегә кадәрге« һәм «шуннан соң». Әлеге көнгә кадәр булган тормыш тәҗрибәм һәм җаным әрнүләрен мин, моннан соңгы чорга үзгәреш кертү максатыннан, спектальгә салдым. … Спекталь – безнең үзебез хакында да. Романны гына түгел, үзебезне дә аңларга кирәк иде…» (Интервью Дамира Сиразиева накануне премьеры, 1987: 4 октября).

Шул рәвешле Чыңгыз Айтматовның әдәби мирасы бөтенхалык байлыгына әверелүен танырга, әлеге процесста әсәрләренең төрле телләргә тәрҗемә ителүенең дә әһәмияткә ия булуына басым ясарга кирәк. Бүгенге көнгә кадәр язучы иҗаты үзенең мәгънәви, эстетик, тарихи кыйммәтен югалтмаган. Икетелле автор буларак Ч.Айтматов милли тел сакланышына, милли әдәбият үсешенә зур өлеш кертә, үз халкының кабатланмас мәдәниятен башка халыкларга таныта, замана өчен бик әһәмиятле булган намус, вождан, мәрхәмәтлелек, кешелеклелек кебек төшенчәләр хакында яза. Аның хакында замандашы, танылган татар язучысы Аяз Гыйләҗев түбәндәге фикерләрне яза: «Чыңгыз Айтматов исеме бөтен кешегә билгеле, бөтен дөнья укучысы өчен кыргыз әдәбияты аның исеменең балкышы белән нурландырылган…» (Гилязов, 2001: 48-53).

Чыңгыз Айтматов үз халнының яшәеш кыйммәтләре аша бөтендөнья өчен әһәмиятле булган төшенчәләрне күтәреп чыкты, шуның белән дөнья әдәбияты дәрәҗәсендә булган югарылыккә иреште.

Татар әдәбиятчыларының тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге аша совет чорында төрки халыкларның бере булган – Чыңгыз Айтматов иҗаты татар халкында да танылу алды, аның горурлыгына әверелде.

Төрки халыклар әдәбиятын бер-берләре теленә тәрҗемә итү өлкәсендәге эш соңгы ике дистә ел өчендә аеруча актив алып барыла. Аеруча бу эш 2000 елларда төрек әдәбияты әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү юнәлешендә башланды. Соңгы дистә елларда татар теленә тәрҗемә үрнәкләре буларак, Асыя Рәхимова тәрҗемәләре: Өмәр Сәйфеттиннең «Вәлинигъмәт – шәфкать иясе», «Биек үкчәләр», Тарык Буграның «Кече Ага» (романнан өзек), шул ук авторның «Улыбыз», Сабахаттин Алиның «Хәсән чоңгылы», Мәхмәт Сейданың «Авылга бәхет китерүче Мәмәт», Шәвкәт Булутның «Язмыги», Беһзат Айның «Мирас бүлешү», Бурһан Гүнәлнең «Кышның хәле башка», Алев Алатлының «Ясминнәр һаман да томаннар артындамы?» («Ясминнәр» романыннан өзек), Орхан Памукның «Өч мушкетер» («Кара китап» романыннан өзек), әлеге авторның «Минем исемем Кызыл» (романнан өзек). «Беренче намаз: төрек һәм төрки шигырьләр, хикәятләр, хикмәтләр, хикәяләр» җыентыгы (Казан, 2010) Бикә Рәхимова тәрҗемәләре: Юныс Әмрәнең (XIII гасыр) «Мөхәммәд» (С.Г.В.), Мәүләнә Җәләлетдин Румидан (XIII гасыр) «Оста белән кылый», «Газраилдән качкан адәм», «Падишаһ һәм аның ике колы», «Кибетче һәм тутый кош», «Алама гадәт, Ач ишәк», Ашык Өмәрнең (XVII гасыр) «Былбыл газап чигә», Ашык Рәйханинең (XX гасыр), «Чакыру», Рамазан Айтанның (XX гасыр) «Ашау» әсәрләре дөнья күрде. Әлеге әдәбият үрнәкләре соңгы елларда төрек әдәбияты белән татар укучыларын таныштыру максатын күз алдында тотып тәрҗемә ителде.

Шунысы уңай күренеш: бүгенге көндә бу эш каршылыклы булып, татар теленнән төрек теленә тәрҗемә итү дә шактый популярлашып бара. Әлеге уңай үзгәрешләр тугандаш халыкларның мәдәни-әдәби якынаюы нәтиҗәсендә мөмкин булды (Сәйфулина, 2014: 322-326).

2005 еллардан башлап татар әдәбияты әсәрләре төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрә башлады. Әлеге әсәрләр исемлегендә беренчеләрдән булып татар әдәбиятының кече эпик әсәрләренең тәрҗемәләрен туплаган «Vasiyet» исемле җыентык игътибарга лаек. «Замбак» нәшриятында әлеге җыентыкның 2005, 2006 һәм 2012 елларда өч басмасы дөнья күрә. Анда кергән әсәрләр профессор Хатыйп Миңнегулов тәкъдиме белән сайланып алынган, китап аның кереш сүзе белән чыга. Җыентыкка тупланган әсәрләр – Фатих Кутлу, Хамза Әрсой, Надир Тамәр Аслан тарафыннан тәрҗемә ителгән. Әлеге җыентыкка татар әдәбиятының иң матур үрнәкләреннән, Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», «Матурлык», Шәриф Камалның «Буранда», «Уяну», Фатих Әмирханның «Бер харәбәдә», «Сәмигулла абзый», Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары», Мирсәй Әмирнең «Мөстәкыйм карт йокысы», Фатих Хөснинең «Сөйләнмәгән хикәя», Миргазиян Юнысның «Безнең өй өянкеләр астында иде» хикәяләре кертелгән. Рәзил Вәлиев әсәрләреннән тупланган «Mavi hüzün»

(«Зәңгәр сагыш») җыентыгы Төркиянең «Da» нәшриятында 2007 елда дөнья күрүе әлеге башлангычның уңай дәвамы буларак бәяләнергә хаклы. Җыентыкны тәрҗемә итүчеләр – Фатих Кутлу һәм Харун Тосун.

Татар әдәбияты әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә итү юнәлешендә беренче адымнарын ясап, шактый нәтиҗәгә ирешкән тәрҗемәче, чыгышы белән Төркиядән булып, бүгенге көндә Казанда яшәүче язучы Фатих Кутлу эшчәнлеге аерым игътибарга һәм өйрәнүгә лаек. Соңгы елларда татар язучыларның шактый әсәрләре аның тарафыннан төрек теленә тәрҗемә ителде. Татар язучыларының шактый әсәрләрен берләштергән җыентыкларның, аерым язучылар әсәрләренең тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрүе – әлеге юнәлештәге эшнең активлашуын күрсәтеп тора. Фатих Кутлуның әлеге юнәлештә эшенең уңай нәтиҗәсе буларак, аның татарның бөек шагыйре –Габдулла Тукай шигырьләрен тәрҗемә итүен күрсәтергә мөмкин. Тәрҗемәченең 2016 елда – Г.Тукайның 130 еллык юбилее уңаеннан 130 шигырен тәрҗемә итеп бастыруы мактауга лаек. Ул төрек халкына 100 елдан соң Тукай исемен кайтарды. Татарның талантлы язучысы А.Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән» («Cuma günü, akşam...») һәм «Өч аршын җир» («Bir avuç toprak»), «Яра» («Yara») әсәрләре дә Фатих Кутлу тарафыннан тәрҗемә ителеп, төрек укучыларына җиткерелде.

Соңгы елларда татар әдәбиятының казах теленә дә шактый күп тәрҗемә ителә башлавы куанычлы. 2015 елда Алматыда басылып чыккан җыентыкта XX йөзъел ахыры язучыларының ике дистәгә якын әсәре тәрҗемә итеп бастырылуы куанычлы күренеш. Казах укучысы тататар әдәбиятыннан Әхәт Гаффар, Фаил Шәфигуллин, Марсел Галиев, Мөхәммәт Мәһдиев, Ринат Мөхәммәдиев, Галимҗан Гыйльман, Ләис Зөлкарнәй, Фәнис Яруллин һәм башка бик күп язучыларның әсәрләрен үз туган телендә уку мөмкинлеген алды.

Шул рәвешле, гасыр дәвамында бер-берсенең хәятеннән шактый аерылышкан төрки халыклар өчен бер-берсен якыннан тану, кардәшлек җепләрен, уртак тамырларны барлауның уңышлы бер юлы буларак, әдәби әсәрләренең тәрҗемәсен булдыру, аларны бастырып чыгару бик уңышлы һәм файдалы, нәтиҗәле эш буларак бәяләнә ала. Үз вакытында Чыңгыз Айтматов әсәрләренең тәрҗемәләре – моның уңай нәтиҗәсе булып тора.

## БИБЛИОГРАФИЯ

Хабутдинова, М. М. (2013). "Личность и творчество чингиза айтматова в оценке татарского писателя аяза гилязова" *Филология и культура. Philology and Culture*. С. 2 (32). б. 270-276.

Бәйрәмова, Ф.Ә. Ана. (2015). *Фәнни-тарихи язма*. Казан: «Аяз»нәшрияты. б. 176.

Фәүзия, Бәйрәмова. (2001). *белән әңгәмә Алты томда. Татар әдәбияты тарихы*. 6 Т. 1960-1990 еллар әдәбияты. Казан: "Раннур". б. 544. http://matbugat.ru/

Фәүзия, Бәйрәмова (2015). Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда: 3 Т. XIX йөз. Казан: Тат.кит.нәшр. б. 551

Миңнегулов, Х.Ю. (2008). "Татарга да тылмач кирәк". *Мәдәни җомга*. б. 10.

Хамидуллин, Л. (2012). "Татарская литература и проблемы перевода" *Идель*. б. 11.

Айтматов, Ч.(1962). *Җәмилә* (пер. на татарский М. Усманова). Казан: Тат.кит. нәшр. б. 88.

Айтматов, Ч. (1965). *Гүзәлем Әсәл* (пер. на татарский Х. Сарьяна). Казан: Тат.кит. нәшр. б. 120.

Саликова, З. (1966). "Интернациональ спектакль туганда". *Социалистик Татарстан*. б. 8.

Илялова, И. (1966). "Гүзәлем Әсәл" *Социалистик Татарстан*. б. 28.

Сахновский-Панкеев, В.(1967). "Возраст театра" *Театр*. С. 9. б. 69-70.

Айтматов, Ч. (1976). *Повестьлар* (пер. на татарский Я. Халитова). Казань: Тат.книж. издат. б. 320.

Айтматов, Ч. (1990). *Бер көн–бер гөмер* (пер. на татарский Р. Ширияздaнова). Казан: Тат. Кит. нәшр. б. 288.

Дамира, Сиразиева (1987). "Интервью накануне премьеры спектакля". 'Ахырзаман' по роману Ч.Айтматова 'Плаха' на сцене ТГАТ им. Г.Камала. *Вечерняя Казань*.

Гилязов, А. (2001). "Мне дороги самые тяжелые годы моей жизни (Взгляд из осени жизни)" *Татарстан*. С. 9. б. 48-53.

Сайфулина, Ф.С. (2014). "Татарско-турецкие культурные и научные взаимосвязи: история и современность". *Филология и культура Philology and Culture*. Казань: КФУ. С. 2 (36). б. 322-326.